ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

№ 691

« 22 » июль 2022 ел

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук сөт җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, шулай ук физик затларга сөт җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау, шулай ук Арча муниципаль районында сыерларның баш санын саклау һәм арттыру буенча чаралар күрү максатыннан, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә.

1.3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның

бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия турында нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә.

2. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлегенә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен районның авыл җирлекләре башлыкларына җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. "Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында" Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 181 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга (04.09.2020 № 687; 13.11.2020 № 897; 19.02.2021 № 94; 16.04.2021 № 283; 01.09.2021 №643; 22.12.2021 № 2268 үзгәрешләр белән).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Д. Шаһиәхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

*ТР Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"22" июнь 22 ел, №691*
*карарына 1 нче кушымта*

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 ел, №112 федераль закон нигезендә эшләнде һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән Арча муниципаль районы территориясендә дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмә субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияне кире кайтару тәртибен, шулай ук субсидия алуга дәгъва кылучы мөрәҗәгать итүчеләрне сайлап алу критерийларын билгели.

3. Субсидия бирү буенча бюджет чараларын баш бүлүче булып Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

4. Гражданнарга субсидия максатчан характерга ия, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.

5. Субсидия алу мөмкинлеге турында халыкка хәбәр итү тиешле мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән башкарыла.

## 2. Субсидия бирү максаты

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 ел, № 112-ФЗ Федераль законның 7 статьясы нигезендә, субсидия бирү максаты-Арча муниципаль районы гражданнарының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларның баш санын саклау өчен шартлар тудыру өлешендә авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеген үстерүгә муниципаль ярдәм күрсәтү.

## 3. Субсидия алу хокукына ия физик затларны сайлау категорияләре һәм критерийлары

Субсидия бирү турында карар кабул итү өчен сайлап алу критерийләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан Арча муниципаль районы территориясендә теркәлгән булырга тиеш;
- субсидия сорап мөрәҗәгать иткән вакытка тиешле авыл җирлегенең хуҗалык кенәгәсендә теркәлгән дүрт һәм аннан күбрәк сыеры булырга тиеш;
- әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегенең 1 пункты таләпләре нигезендә граждан тарафыннан документлар пакетын тапшыру.

## 4. Субсидия бирү комиссиясе

1. Арча муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидия бирү буенча даими эшләүче комиссия (алга таба - Комиссия) рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2. Комиссия секретаре комиссиянең утырышларын әзерли, утырыш беркетмәсен алып бара.

3. Комиссия утырышлары ай саен уздырыла.

4. Өч эш көне дәвамында рәсмиләштерелә торган Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә субсидияләр бирү турында карар әзерләнә.

5. Комиссия карарлары аның әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше утырышта катнашканда һәм утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 5. Субсидия бирү шартлары

1. Субсидия алу хокукын алу өчен граждан (гражданка) Арча муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - Башкарма комитет) Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә, түбәндәге документлар белән гариза тапшыра:

**1.1 күчермәләр:**

-шәхесне раслаучы документ;

- ИНН таныклыгы;

- сату-алу шартнамәсе;

- сатып алынган саву аппаратының тулы бәясен түләүне раслаучы түләү документлары (квитанция, касса чегы яки банк өземтәсе һәм түләү поручениесе);

- җиһазның (аппаратның) паспорты;

1.2 гариза бирү датасына сыерлар санын күрсәтеп, авыл җирлеге башлыгы раслаган хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

1.3 субсидия күчерү өчен шәхси счет номеры;

1.4 салым инспекциясе тарафыннан таныкланган № КНД 20101 формасы буенча салымнарның барлык төрләре буенча бурыч булмау турында белешмә;

1.5 Авыл җирлеге башлыгы тарафыннан таныкланган үзара салым буенча бурыч булмау турында белешмә.

2. Башкарма комитет гаризаларны теркәү журналында, кергән номерын һәм тапшыру датасын күрсәтеп, гаризаны терки, бирелгән барлык гаризаларны һәм документларны аларның тулылыгы һәм дөреслеге предметына карый һәм комиссия утырышына чыгара.

Комиссия ай саен субсидия бирү буенча тапшырылган гаризаларны карый, субсидия бирү турында коллегиаль карар кабул итә. Нәтиҗә беркетмә нигезендә рәсмиләштерелә, аның нигезендә Башкарма комитет субсидия алучылар исемлеген раслау турында карар чыгара.

3. Субсидия гариза бирү елында сатып алынган саву аппараты бәясенең 50%ы күләмендә бирелә, әмма дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган бер шәхси ярдәмче хуҗалык өчен 20000 сумнан артмый һәм бер мәртәбә бирелә.

4. Субсидия алучылар исемлеге расланганнан соң, Башкарма комитет әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә, субсидия бирү турында граждан белән килешү төзи.

5. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- тулы булмаган документлар комплектын тапшыру яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;
- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;
- бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитмәгән очракта, субсидия гариза бирү чираты тәртибендә бирелә.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Башкарма комитет мондый карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә шәхси ярдәмче хуҗалыкка тиешле хәбәрнамә җибәрә.

## 6. Субсидия бирү тәртибе

1. Субсидия алу өчен Башкарма комитет билгеләнгән форма буенча субсидия алу хокукына ия гражданнарның җыелма реестрын формалаштыра һәм Финанс-бюджет палатасына тапшыра (Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы).

2. Субсидия бирү комиссия карары нигезендә әзерләнгән субсидия алучылар исемлеген раслау турында Башкарма комитет карары, субсидия бирү турындагы килешү нигезендә бюджет акчаларын баш бүлүченең – Башкарма комитетның шәхси счетыннан гражданнарның шәхси счетларына акча күчерү юлы белән башкарыла.

## 7. Субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияне кире кайтару тәртибе

1. Субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр биргән очракта, Башкарма комитет биш эш көне эчендә субсидия алучы адресына субсидияне муниципаль район бюджетына кире кайтаруны таләп итеп хәбәрнамә җибәрә.

1.1. Субсидия алучы, таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә муниципаль район бюджетына алынган субсидия суммасын кире кайтарырга тиеш, ул муниципаль район бюджеты керемнәренә күчерелергә тиеш.

1.2. Субсидия күрсәтелгән срокка кайтарылмаган очракта, Башкарма комитет муниципаль район бюджетына кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасын суд тәртибендә түләттерү буенча чаралар күрә.

1.3. Башкарылган чыгымнар турында дөрес булмаган мәгълүмат биргән өчен гражданнар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.

2. Субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшереп торуны, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, бюджет чараларын баш башкаручы буларак, Башкарма комитет һәм Арча муниципаль районының финанс контроле органнары башкара.

3. Субсидия алучы 5 ел дәвамында саву аппаратын төзек хәлдә сакларга һәм юнәлеше буенча кулланырга тиеш.

*Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта*

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә

Кемнән
_____________________________________________
_________________________________ яшәүче
_____________________________________________
паспорт №_______ сериясе _____________
бирелгән______________________________________
ИНН _________________________________________
тел.______________________________________

**Гариза**

Арча муниципаль районы Башкарма комитетның «___» ________________ 2022 ел, №___карары белән расланган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидия бирү турындагы нигезләмә нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидия бирүегезне сорыйм.

_________________________адресы буенча урнашкан шәхси хуҗалыкта савым сыерлар саны ___________ 2022 елга _________ баш тәшкил итә.

1. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе белән таныш һәм килешәм.

2. Субсидия бирелгән очракта, түбәндәгеләргә бурычлымын:

а) субсидия алганнан соң биш ел эчендә савым сыерларының баш санын киметмәскә.

Гаризага терким:

1. Күчермәләр:

- шәхесне таныклый торган документ;
- ИНН таныклыгы;
- саву аппаратын сату-алу шартнамәсе;
- сатып алынган саву аппаратының тулы бәясен түләүне раслый торган түләү документы;
- җиһазның (аппаратның) паспорты;

2. _______________________ 2022 елга (гариза бирү датасы) сыерларның баш санын күрсәтеп, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

3. Субсидия күчерү өчен шәхси счет номеры;

4. Салым инспекциясе тарафыннан таныкланган №КНД 1120101 формасы буенча салымнарның барлык төрләре буенча бурычлар булмау турында белешмә;

5. Үзара салым буенча бурыч булмау турында белешмә.

Югарыда аталган субсидияне тәэмин итү максатыннан минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Субсидияне түбәндәге реквизитлар буенча күчерүегезне сорыйм:

________________________________________________________________________

____________________________________________________________________

"____" __________20____ел

____________ /_______________/

(имза) (Ф. и. а.и.)

*Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы*
*һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым*
*сыеры булган гражданнарга саву*
*аппараты сатып алуга чыгымнарның*
*бер өлешен каплауга субсидия бирү*
*турында нигезләмәгә 2 нче кушымта*

**20____ елга Арча муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнар**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| № т/б | Мөрәҗәгать итүченең ф. и. а.и. | ИНН | паспорт сериясе, номеры | Яшәү адресы, яшәү урыны буенча теркәлү | Шәхси ярдәмче хуҗалыкта сыерлар саны, гариза бирү датасына баш саны | Субсидия күләме | Банк реквизи тлары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Комиссия секретаре ____________________ ______________________

(имза)

*Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы*
*һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым*
*сыеры булган гражданнарга саву*
*аппараты сатып алуга чыгымнарның*
*бер өлешен каплауга субсидия бирү*
*турында нигезләмәгә 3 нче кушымта*

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү турында килешү**

Арча шәһәре

"____"___________20__ ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе__________________исеменнән Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы бер яктан, __________________________________________________________, алга таба «Субсидия алучы» дип аталучы икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне (алга таба – килешү) төзеделәр:

**1. Килешү предметы**

1.1. Килешү предметы булып шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм аннан файдалану тора.

1.2. 2022 елда субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме _____________________ сум.

**2. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Башкарма комитет бурычлы:

а) субсидия алучыга________________________ күләмендә субсидия бирергә;

б)әлеге килешү кысаларында субсидия алучының сыерларының баш санын тикшерергә.

в) субсидия алучыдан әлеге килешү предметына кагылышлы документларны һәм материалларны соратып алырга.

г) субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерергә.

2.3. Гариза бирүче бурычлы:

а) субсидия алганнан соң сыерларның баш санын биш ел эчендә киметмәскә;

б) Башкарма комитет тарафыннан субсидиянең максатчан

кулланылышын тикшергәндә, барлык кирәкле документларны һәм мәгълүматны тапшырырга.

2.4. Субсидия алучы бюджет акчаларын төп бүлүче тарафыннан бюджет чараларын гамәлгә ашыруга һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүгә риза.

## 3. Якларның җаваплылыгы

3.1. Әлеге килешү шартларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге килешү аңа ике Як тарафыннан да кул куелган көннән үз көченә керә һәм ______________________ елга кадәр гамәлдә була.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәү барышында Яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр (каршылыклар), мөмкин булганча, сөйләшүләр үткәрү, хатлар һәм башка документлар алмашу юлы белән яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә яки суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Әлеге килешү Якларның һәркайсы өчен бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

5.3. Килешүнең барлык кушымталары да аның аерылгысыз өлеше булып тора.

## 6. Якларның адреслары һәм реквизитлары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты | Субсидия алучы |
| __________________/ _________________ | ________________/________________ |
| М. У. | |

*Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы*
*һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым*
*сыеры булган гражданнарга саву*
*аппараты сатып алуга чыгымнарның*
*бер өлешен каплауга субсидия бирү*
*турында нигезләмәгә 4 нче кушымта*

______________________________
______________________________
______________________________,
Мөрәҗәгать итүченең контакт
мәгълүматлары

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга савым аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирүдән баш тарту турында**

**ХӘБӘРНАМӘ**

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәге нигезләр буенча шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидия бирүдән баш тарту турында хәбәр итә:
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________

Башкарма комитет җитәкчесе _____________ _________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

Башкаручы:
Ф. И. А.И.,
телефон, электрон почта адресы

*ТР Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"22" сентябрь ел, №691*
*карарына 2 нче кушымта*

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирүгә юнәлдерелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Шаһиәхмәтов Радик Дамирович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәбибуллина Гөлназ Ринатовна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге баш белгече, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Абдуллин Ленар Илсурович | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Галимова Светлана Петровна | "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы" МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Галимуллина Гүзәл Харисовна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы; |
| Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна | - Татарстан Республикасы Арча район Советының юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сафиуллина Надия Равиловна | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисе (килешү буенча). |

*ТР Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"22" июль ел, №691*
*карарына 3 нче кушымта*

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга юнәлдерелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия турында нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

Арча муниципаль районының дүрт һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган гражданнарына саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга юнәлдерелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча комиссия (алга таба – Комиссия) дүрт һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларда саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга дәгъва кылучыларның гаризаларын карау һәм савым сыерлары санын саклап калу буенча хуҗалык итүче субъектларны стимуллаштыруга юнәлтелгән җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында төзелде.

**2. Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары**

Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары:

– Арча муниципаль районы гражданнарының 4 һәм аннан күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыкларда саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплауга гаризаларын карау;

– җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту;

– субсидия күләмен билгеләү критерийлары буенча карар кабул итү нигезендә савым сыерларының баш санын саклап калуга юнәлдерелгән чараларны матди кызыксындыру.

**3. Комиссиянең вәкаләтләре**

Комиссия әлеге Нигезләмәдә каралган билгеле бер критерийлар кысаларында карар кабул итү вәкаләтләренә ия.

**4. Субсидия күләмен билгеләү критерийлары**

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм дүрт һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнарның бер өлешен каплау күләме (субсидия күләме) сатып алына торган саву аппараты бәясенең 50%ыннан артмаска тиеш, әмма 20000 сумнан артык түгел.

Комиссия утырышы комиссиянең һәр әгъзасы кул куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

**5. Йомгаклау нигезләмәсе**

Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.